КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 март г.Казань № 164

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурслары турында» 2018 ел, 1 октябрь, 889 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурслары турында» 2018 ел, 1 октябрь, 889 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы

архивы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсларының конкурс комиссиясе составында:

комиссия составыннан А.А.Фоминны, Г.Р.Нигъмәтуллинаны, Р.А.Шәйхетдиновны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Рәхимьян кызы Вәлиеваны (килешү буенча);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе секретаре Гөлнара Фәрит кызы Минҗанованы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы Ләйсән Гаптелхан кызы Низамованы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин